Поздравление

Автор: Administrator
03.10.2014 22:05

Central Muslim Spiritual Board of Russia

Центральное духовное управление мусульман России
(ЦДУМ России)
WWW.CDUM.RU

450057, г. Уфа, ул. Тукаева, 50
тел. (347) 250-8086, 250-80-79, ф. 250-80-99
129301, г. Москва, ул. Касаткина, д. 18 стр. 1
тел.(495) 661-35-52, ф. (495) 686-30-94

04.10.2014 г.

Корбан гаете мөнәсәбәте илә, тәбрик.
Мөхтәрәм Гәдельша хәзрәт!

Русия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте һәм аңа табигъ мәхәлләләре исеменнән җөмләгезне Гайдүл-Әдха — Корбан бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итәм. Җәнабел Хак хәерле гамәлләр, күркәм тормыш, ил-көн тынычлыгы, һәр ике дөнья сәгадәтләрен насыйп әйләсен.

Җир йөзендә яшәгән бәндәләр, бөтенебез дә атабыз Адәм галәйһиссәлам, анабыз һавадан. Шуны аңлап, бер-беребезнең хәлен белеп тынычлык-иминлектә яшәдек исә, һичшиксез Аллаһы Раббыбызның рәхмәт һәм ризалыгына ирешербез. Аллаһы Раббыбызга якын булырбыз, иншә Аллаһ.

Бу мөбарәк олуг бер бәйрәм. Шуның өчен дә бәйрәм таңында җир йөзенең мәшрикъ-мәгърибеннән хаҗиларыбыз Гарәфәт тавында, без исә нурлы, ямьле мәсҗидләребездә: "Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, Лә иләһә иллаллаһү үәллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, үә лилләһил-хәмде", дип тәкъбир авазлары белән күкләрне яңгыратып, вәхшият һәм ерткычлыктан аерылуга, бәндә икәнлегебезне аңлап, яшәү кадерен тануга сәбәп бәйрәмебезгә куанабыз.

Мөхтәрәм хәзрәт! Корбан бәйрәме белән сезне ихлас котлыйм. Аллаһы Тәбәрәкә вә Тәгалә күңелләребезгә һәм гаиләләребезгә, мәхәллә-мәсҗидләребезгә, авыл һәм шәһәрләребезгә, газиз Ватаныбыз һәм бөтен Галәмгә тынычлык-иминлек, муллык һәм бәрәкәт насыйп әйләсен. Җөмләбезгә хәерле гомер һәм гамәлләр, әһел һәм балаларыбызга Раббуль Гыйззә тәүфыйк-истикамәтләр, шәкертләребезгә файдалы гыйлемнәр, дин һәм милләтебезгә хәерле хезмәтләр миәссәр кылып, җөмләбезнең күңелләрен пакь, иманнарыбызны сәламәт кылсын.

Корбан-шәриф бәйрәмебез җөмләбезгә мөбарәк булсын!

Хәер дога, изге теләкләр белән,

Шәйхел-Ислам
Тәлгат Сафа Таҗетдин,
Баш мөфти
Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе